ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 маенда
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле $13^1$ өлеш өстәргә:
“$13^1$. “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә тиешле территориядә инвалидлык төркемнәре һәм организм функцияләренең тотрыклы зәгыйфьлекләренең түбәндәге төрләре: күрү сәләте (сукырлар һәм начар күрүчеләр), ишетү сәләте (ишетмәүчеләр), терәк-хәрәкәт аппараты (аяк яисә кул функцияләре шактый нык бозылган затлар) буенча инвалид, кресло-коляскаларда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп, булган сайлаучыларның саны турында белешмәләр инвалидларның федераль реестры белешмәләре нигезендә Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан һәр елның 1 гыйнварына һәм 1 июленә тиешле ай эчендә түбәндәгеләргә тапшырыла:
1) Татарстан Республикасы буенча – Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә;
2) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре буенча – Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә.”;
б) түбәндәге эчтәлекле $13^2$ өлеш өстәргә:

“13². “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инвалидларны социаль яклау һәм аларга социаль ярдәм итү өлкәсендәге органы, инвалид булган Россия Федерациясе гражданнарының организм функцияләренең тотрыклы зәгыйфьлекләрен исәпкә алып, аларның сайлау хокукларын тәэмин итү эшендә сайлау комиссияләренә, шулай ук шушы орган һәм сайлау комиссияләре арасында төзелә торган килешү нигезендә кирәкле ярдәм күрсәтүдә күрсәтелгән гражданнарга ярдәм итәргә тиеш.”;

2) 11 статьяга түбәндәге эчтәлекле 11 өлеш өстәргә:

“11. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең, территориаль, участок комиссиясенең вәкаләтләр чоры сайлау кампаниясе, референдум кампаниясе вакытында тәмамланса, мондый сайлау комиссиясенең яңа составы сайлаулар, референдум нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көнгә кадәр төзелми. Сайлау комиссиясенең яңа составы буенча тәкъдимнәр кабул итү вакыты 30 көн тәшкил итә, һәм ул сайлаулар, референдум нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көннән иртәрәк башланмаска һәм сайлаулар, референдум нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көннән алып 60 көннән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиеш. Яңа составта төзелгән сайлау комиссиясе үзенең беренче утырышына сайлау кампаниясе, референдум кампаниясе тәмамланган көннән соң 10 көн эчендә җыела.”;

3) 16 статьяда:

а) 5 өлештә “Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе” сүзләрен “Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның карары буенча территориаль комиссияләр” сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 6² өлеш өстәргә:

“6². Әлеге Кодексның 27 статьясындагы 3 һәм 3¹ өлешләрендә каралган очракларда сайлау участоклары исемлеген төгәлләштерү нәтиҗәсендә төзелгән сайлау участокларында участок комиссияләре – сайлау кампаниясе чорыннан башка вакытта сайлау участоклары исемлеген төгәлләштерү турында карар кабул ителгән көннән алып 60 көн эчендә, ә сайлау кампаниясе чорында тавыш бирү көненә кадәр 35 көннән дә соңга калмыйча төзеләләр. Аларның составы буенча тәкъдимнәр кабул итү вакыты 30 көн тәшкил итә.”;

4) 17 статьяның 9 өлешендә “Округ сайлау комиссиясе” сүзләрен “Округ комиссиясе” сүзләренә алмаштырырга;

5) 18 статьяның 19 өлешендәге 4 пунктында “сайлаучылар исемлекләре,” сүзләреннән соң “үзенең булу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертү турында гаризалар биргән сайлаучылар хакындагы белешмәләр,” сүзләрен өстәргә;

6) 22 статьяда:

а) 1 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Сайлаулар үткәргәндә күзәтүче һәр теркәлгән кандидат, теркәлгән кандидатны, теркәлгән кандидатларны күрсәткән сайлау берләшмәсе, кандидатлар исемлеген теркәгән сайлау берләшмәсе, шулай ук Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан билгеләп куелырга мөмкин.”;

б) 3 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Күзәтүченең вәкаләтләре аны билгеләп куйган теркәлгән кандидат яисә аның ышанычлы заты, сайлау берләшмәсе, иҗтимагый берләшмә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан бирелгән язмача юлламада таныкланырга тиеш.”;

в) 3[1] өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Участок комиссияләренә күзәтүчеләр билгеләп куйган сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, теркәлгән кандидат тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча билгеләп куелган күзәтүчеләр исемлеген – тиешле территориаль комиссиягә, ә җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәргәндә муниципаль берәмлекнең тиешле сайлау комиссиясенә тапшыра.”;

г) 5 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, теркәлгән кандидат яисә федераль законда каралган очракларда теркәлгән кандидатның ышанычлы заты һәр комиссиягә тавыш бирү бинасында күзәтүне чират буенча башкарырга хокуклы иң күбе ике күзәтүче билгеләп куярга хокуклы.”;

д) 6 өлешнең 8 пунктында “сайлау берләшмәсенең,” сүзләреннән соң “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының,” сүзләрен өстәргә;

7) 27 статьяда:

а) 2 өлештә “биш елга” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 өлешнең өченче җөмләсен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 3[1] өлеш өстәргә:

“3[1]. Сайлау участоклары исемлеге һәм аларның чикләре аларны төзү өчен каралган тәртиптә түбәндәге очракларда төгәлләштерелергә мөмкин:

1) муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртү, аларны үзгәртеп кору, бетерү;

2) сайлау участогы территориясендә теркәлгән сайлаучылар санының кимүе (50гә кадәр һәм аннан да кимрәк);

3) сайлау участогында сайлаучыларның максималь санын мең ярымга кадәр киметү максатларында;

4) сайлау участогында сайлаучыларның максималь санын өч меңгә кадәр арттыру максатларында;

5) яңа күпфатирлы йортларны һәм торак йортларны файдалануга кертүне яисә тавыш бирү биналарын алмаштыру кирәклеген исәпкә алып, сайлаучылар өчен иң уңайлы шартларны тәэмин итү максатларында.”;

г) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ өлеш өстәргә:

“$3^2$. Сайлау участоклары исемлеген һәм (яисә) аларның чикләрен төгәлләштерү турында карар – сайлау кампаниясе чорыннан башка вакытта, ә аерым очракларда гына тавыш бирү көненә кадәр 70 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш. Әлеге статьяның $3^1$ өлешендәге 3, 4 яисә 5 пунктларында каралган очракта карар биш елга бер мәртәбә кабул ителергә мөмкин.”;

д) түбәндәге эчтәлекле $3^3$ өлеш өстәргә:

“$3^3$. “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә әлеге статьяның $3^1$ өлешендәге 3, 4 яисә 5 пунктларын гамәлгә ашыру максатларында кабул ителә торган карарда муниципаль район, шәһәр округы чикләрендә сайлау участоклары санын арттыру каралса, күрсәтелгән карар Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе һәм аннан соң Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп кенә кабул ителергә мөмкин. Федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар буенча сайлау кампаниясе чорында мондый карарны кабул итү рөхсәт ителми.”;

8) 29 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Конкрет сайлау участогы территориясендә Россия Федерациясе гражданының яшәү урыны булу факты, ә “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, башка федераль законда, әлеге Кодекста каралган очракларда – гражданның әлеге участок территориясендә булу (вакытлыча булу) факты (граждан актив сайлау хокукына ия булганда) аны шушы участокта сайлаучылар исемлегенә кертү өчен нигез була. Гражданның аерым сайлау участогы территориясендә яшәү урыны йә булу (вакытлыча булу) урыны булу факты – Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе чикләрендә Россия Федерациясе гражданнарының яшәү урыны һәм булу урыны буенча теркәлүен исәпкә алучы органнар, ә “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, башка федераль законда, әлеге Кодекста каралган очракларда шуңа вәкаләтле органнар, оешмалар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан билгеләнә. Россия Федерациясе гражданын аның аерым сайлау участогы территориясендәге булу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертү әлеге Кодексның 76 статьясындагы 18 өлеше нигезендә башкарыла.”;

б) 6 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) 7 өлештә “округ сайлау комиссияләренә” сүзләрен “округ комиссияләренә” сүзләренә алмаштырырга;

г) 10 өлештә “округ сайлау комиссиясе” сүзләрен “округ комиссиясе” сүзләренә алмаштырырга;

д) 12 өлештә “округ сайлау комиссиясенең” сүзләрен “округ комиссиясенең” сүзләренә алмаштырырга;

е) 13 өлештә “округ сайлау комиссиясе” сүзләрен “округ комиссиясе” сүзләренә алмаштырырга;

ж) 17 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“17. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәргәндә тавыш бирү көнендә хастаханәләрдә яисә шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында булачак сайлаучылар, шулай ук хәрби часть урнашкан урыннан читтәге хәрби хезмәткәрләр арасыннан булган сайлаучылар тавыш бирү көненә кадәрге көнне җирле вакыт буенча 14 сәгатьтән дә соңга калмыйча участок комиссиясенә шәхсән бирелгән язма гаризалары буенча участок комиссиясе карары белән аларның вакытлыча булу урыны буенча сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелергә мөмкин.

Җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәргәндә вакытлыча булу урыннарындагы, өзлексез циклда эшләүче предприятиеләрдә хезмәт куючы һәм эш (смена) дәвамлылыгын киметү мөмкин булмаган аерым төр эшләр белән шөгыльләнүче сайлаучылар, шулай ук хәрби часть урнашкан урыннан читтәге хәрби хезмәткәрләр арасыннан булган сайлаучылар тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча участок комиссиясенә шәхсән бирелгән язма гаризалары буенча участок комиссиясе карары белән аларның вакытлыча булу урыны буенча сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелергә мөмкин.

Сайлаучыны аның вакытлыча булу урыны буенча сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертү турында мәгълүмат әлеге сайлаучы үзенең яшәү урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогының участок комиссиясенә, шул исәптән “Сайлаулар” ДАСны кулланып, тапшырыла. Участок комиссиясе сайлаучылар исемлегенең тиешле юлында: “______ номерлы сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелде” дигән тамга куя, сайлау участогының номерын күрсәтә.”;

9) 36 статьяның 5 өлешендә “округ сайлау комиссияләренә” сүзләрен “округ комиссияләренә” сүзләренә алмаштырырга;

10) 41 статьяның $1^1$ өлешендә “округ сайлау комиссиясенең” сүзләрен “округ комиссиясенең” сүзләренә алмаштырырга;

11) 44 статьяда:

а) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9. Сайлаучы имзалар кәгазендә үз имзасын куя һәм аны кую датасын, шулай ук фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын (тавыш бирү көнендә 18 яшь тулса – өстәмә рәвештә туган числосын һәм аен), яшәү урыны адресын, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен, номерын күрсәтә. “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 2 статьясындагы 5 пунктчасында күрсәтелгән реквизитларның (Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункт, урам исеме, йорт һәм фатир номеры) нинди дә булса берсенең булмавы, сайлаучының яшәү урынының

факттагы үзенчәлекләрен исәпкә алып, шушы реквизитны бертөрле генә аңлауга комачауламаган очракта, яшәү урыны адресында күрсәтелгән реквизитларның нинди дә булса берсе булмаска мөмкин. Имзалар кәгазендә үз имзасын куйган һәм аны кую датасын күрсәткән сайлаучы турында белешмәләр сайлаучы үтенече буенча кандидатны, кандидатлар исемлеген хуплап имзалар җыюны башкаручы зат тарафыннан имзалар кәгазенә кертелергә мөмкин. Мондый белешмәләр бары тик кулдан язып куела, бу очракта карандаш куллану рөхсәт ителми. Сайлаучы имзасын һәм аны кую датасын үз кулы белән яза. Әгәр сайлаучы инвалид булса, шуңа бәйле рәвештә имзалар кәгазендә мөстәкыйль рәвештә үз имзасын куя алмаса һәм аны кую датасын күрсәтә алмаса, ул комиссия әгъзасы, кандидат, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле, кандидатның, сайлау берләшмәсенең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле, ышанычлы заты булмаган башка сайлаучы ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Бу очракта сайлаучыга ярдәм итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе һәм номеры имза куела торган графада күрсәтелергә тиеш. Сайлаучы төрле кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен күрсәтүне хуплап имза куярга хокуклы, әмма бер үк кандидатны, кандидатлар исемлеген хуплап бары тик бер генә имза куярга хокуклы.";

б) 10 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 2 статьясындагы 5 пунктчасында күрсәтелгән реквизитларның (Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункт, урам исеме, йорт һәм фатир номеры) нинди дә булса берсенең булмавы, сайлаучылар имзаларын җыюны башкаручы затның яшәү урынының факттагы үзенчәлекләрен исәпкә алып, шушы реквизитны бертөрле генә аңлауга комачауламаган очракта, яшәү урыны адресында күрсәтелгән реквизитларның нинди дә булса берсе булмаска мөмкин.";

12) 64 статьяның 4 өлешендә "әлеге материалларны әзерләгән һәм аларга заказ биргән оешманың (затның) урнашкан урыны турында (яшәү урыны адресы турында) белешмәләр" сүзләрен "әлеге материалларны әзерләгән һәм аларга заказ биргән юридик затның адресы, индивидуаль эшкуарның адресы (физик затның яшәү урыны адресы) турында белешмәләр" сүзләренә алмаштырырга;

13) 72 статьяның 1 өлешендә:

а) 2 пунктта "округ сайлау комиссияләре" сүзләрен "округ комиссияләре" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктта "округ сайлау комиссияләре" сүзләрен "округ комиссияләре" сүзләренә алмаштырырга;

14) $73^1$ статьяда:

а) 2 өлештә "территориаль комиссиядә (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә, округ сайлау комиссиясендә)" сүзләрен "муниципаль берәмлекнең

сайлау комиссиясендә (округ комиссиясендә)” сүзләренә алмаштырырга, “бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын” сүзләре татарча текстта үзгәрешсез кала;

б) 7 өлештә “стационар дәвалау-профилактикалау учреждениесе администрациясе тарафыннан (әгәр сайлаучы шул учреждениедә дәвалана торган булса),” сүзләреннән соң “халыкны социаль яклау органы җитәкчесе тарафыннан (әгәр сайлаучы инвалид булса),” сүзләрен өстәргә;

в) 10 өлештә “территориаль комиссия (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы” сүзләрен “муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе) рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы” сүзләренә, “Территориаль комиссия (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе)” сүзләрен “Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе)” сүзләренә, “"Территориаль комиссиядә (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә, округ сайлау комиссиясендә)_____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды"” сүзләрен “"Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә (округ комиссиясендә) _____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды"” сүзләренә алмаштырырга;

15) 75 статьяда:

а) 11 өлештә “, 8” санын төшереп калдырырга;

б) 12 өлештә “, 8” санын төшереп калдырырга;

в) 16 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: “Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары булган йә әлеге Кодексның 76 статьясындагы 18 өлешендә билгеләнгән тәртиптә үзенең булу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертү турында гаризалар биргән күп санлы сайлаучылар көтелә торган сайлау участогында, шулай ук 500дән кимрәк сайлаучы теркәлгән һәм бюллетеньнәрне эшкәртүнең программа-техник комплекслары кулланыла торган сайлау участогында бюллетеньнәрнең саны тиешле комиссиянең карары буенча арттырылырга мөмкин.”;

16) 76 статьяда:

а) 3 өлештә “, ә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәргәндә – шулай ук шушы сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар саны, үзенең башка сайлау участогында булу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертү турында гариза бирүгә бәйле рәвештә сайлаучылар исемлегеннән төшереп калдырылган сайлаучылар саны, шулай ук үзенең шушы сайлау участогында булу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертү хакында гаризалар биргән сайлаучылар саны турында мәгълүмат бирә” сүзләрен өстәргә;

б) 15 өлештә “һәм мондый факт суд тәртибендә расланса” сүзләрен төшереп калдырырга, аңа түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: “Участок комиссиясе әгъзасын шушы комиссия эшендә катнашудан читләштерү, күзәтүчене

яисә башка затны тавыш бирү бинасыннан чыгару турында карар суд тарафыннан участок комиссиясенең урнашу урыны буенча кабул ителә.”;

в) түбәндәге эчтәлекле 18 өлеш өстәргә:

“18. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәргәндә тавыш бирү көнендә үзенең яшәү урыныннан читтә булачак сайлаучы “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә сайлау комиссиясенә үзенең булу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертү турында гариза (алга таба шушы өлештә – гариза) бирергә хокуклы. Гариза сайлаучы тарафыннан, паспорт (паспортны алмаштыру вакытында – вакытлыча бирелгән шәхес таныклыгы) күрсәтеп, шәхсән генә бирелергә мөмкин. Гариза биргән сайлаучы үзенең яшәү урыны буенча сайлаучылар исемлегеннән төшереп калдырыла. Гариза биргән сайлаучы үзенең булу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә бер генә сайлау участогында кертелергә мөмкин. Гариза биргән һәм тавыш бирү көнендә үзенең яшәү урыны буенча сайлау участогына килгән сайлаучы сайлаучылар исемлегенә участок комиссиясе карары белән генә һәм аның үзенең булу урыны буенча сайлау участогында тавыш бирмәгәнен раслый торган фактны билгеләгәннән соң гына кертелергә мөмкин. Сайлаучыны үзенең яшәү урыны буенча сайлаучылар исемлегенә керткән очракта, ул үзенең булу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә керү хокукын югалта.”;

17) $76^1$ статьяда:

а) 1 өлештә “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына,” сүзләрен төшереп калдырырга, “территориаль комиссия (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе)” сүзләрен “муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе)” сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органнарына сайлауларда тавыш бирү көне законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда тавыш бирү көне белән берләштерелгән очракта, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирү үткәрелми. Җирле үзидарә органнарына күрсәтелгән сайлауларны үткәргәндә, сайлау округының чикләре бер сайлау участогы кысаларында булган сайлаулардан тыш, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү үткәрелә.”;

в) 4 өлештә “Территориаль комиссия (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе)” сүзләрен “Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе)” сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 өлештә “территориаль комиссия,” сүзләрен төшереп калдырырга, “округ сайлау комиссиясе” сүзләрен “округ комиссиясе” сүзләренә алмаштырырга;

д) 7 өлештә “территориаль комиссиянең,” сүзләрен төшереп калдырырга, “округ сайлау комиссиясенең” сүзләрен “округ комиссиясенең” сүзләренә алмаштырырга;

е) 8 өлештә “территориаль комиссия,” сүзләрен төшереп калдырырга, “округ сайлау комиссиясе” сүзләрен “округ комиссиясе” сүзләренә алмаштырырга;

ж) 9 өлештә “Территориаль комиссия (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе)” сүзләрен “Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе)” сүзләренә алмаштырырга;

з) 10 өлештә “территориаль комиссия,” сүзләрен төшереп калдырырга, “округ сайлау комиссиясе” сүзләрен “округ комиссиясе” сүзләренә алмаштырырга;

и) 11 өлештә “территориаль комиссия,” сүзләрен төшереп калдырырга, “округ сайлау комиссиясе” сүзләрен “округ комиссиясе” сүзләренә алмаштырырга;

к) 12 өлештә “территориаль комиссия,” сүзләрен төшереп калдырырга, “округ сайлау комиссиясе” сүзләрен “округ комиссиясе” сүзләренә алмаштырырга;

18) 77 статьяның 14 өлешендәге икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Участок комиссиясе комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия булган кимендә ике әгъзасына, төрле кандидатлар, сайлау берләшмәләре, иҗтимагый берләшмәләр, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан билгеләп куелган күзәтүчеләргә тавыш бирү урынына бару буенча участок комиссиясенең тавыш бирүне үткәрү өчен бинадан читкә чыгып йөрүче хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары белән бертигез мөмкинлекләр тудырырга тиеш.”;

19) 78 статьяда:

а) 2 өлешнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5) түбәндәге тәртиптә беркетмә юллары:

1 юл: тавыш бирү тәмамланган вакытка сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар саны;

2 юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәр саны;

2а юл: вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларга, шул исәптән 2б юлда аерым – муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе) бинасында, бирелгән бюллетеньнәр саны;

3 юл: сайлаучыларга тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында бирелгән бюллетеньнәр саны;

4 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

5 юл: юкка чыгарылган бюллетеньнәр саны;

6 юл: тавыш бирү өчен күчерелмә әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

7 юл: тавыш бирү өчен стационар әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

8 юл: гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны;

9 юл: гамәлгә яраклы бюллетеньнәр саны;

10 юл: юкка чыккан бюллетеньнәр саны;

11 юл: алганда исәпкә алынмаган бюллетеньнәр саны.

Әлеге Кодекс нигезендә вакытыннан алда тавыш бирү үткәрелмәгән очракта, 2а һәм 2б юллары тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәдә язылмыйлар.";

б) 3 өлештә "14 юлына" сүзләрен "12 юлына" сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә "14 юлына" сүзләрен "12 юлына" сүзләренә алмаштырырга;

г) $4^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"$4^1$. Әлеге Кодексның $76^1$ статьясындагы 2 өлешендә каралган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү үткәрелгән очракта, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә шулай ук түбәндәге юллар өстәлә:

9а юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9б юл: тавыш бирү көненә кадәр участок комиссиясе тарафыннан сайлаучыларга сайлау участогында бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9в юл: сайлау участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән сайлаучылар саны;

9г юл: сайлау участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9д юл: муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе) тарафыннан сайлаучыларга бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9е юл: юкка чыккан бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.";

20) 79 статьяда:

а) 3 өлештә "7 юлына" сүзләрен "5 юлына" сүзләренә, "11г юлына" сүзләрен "9г юлына" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "территориаль комиссия (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе)" сүзләрен "муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе)" сүзләренә, "11а юлына" сүзләрен "9а юлына" сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәргәндә, сайлаучыларның тавышларын санау алдыннан участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары сайлаучылар исемлегенең һәр битенә шушы биттәге түбәндәге суммар күрсәткечләрне кертәләр:

1) тавыш бирү тәмамланган вакытка сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар санын (нинди дә булса сәбәпләр аркасында киткән сайлаучылар санын исәпкә алмыйча);

2) сайлаучыларга тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында бирелгән бюллетеньнәр санын (сайлаучылар исемлегендәге сайлаучылар имзалары саны буенча билгеләнә);

3) тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр санын (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә).";

г) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

“5[1]. Җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәргәндә, сайлаучыларның тавышларын санау алдыннан участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары сайлаучылар исемлегенең һәр битенә шушы биттәге түбәндәге суммар күрсәткечләрне кертәләр:

1) тавыш бирү тәмамланган вакытка сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар санын (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе) һәм участок комиссиясе тарафыннан бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирелгән, шулай ук башка сәбәпләр аркасында киткән сайлаучылар санын исәпкә алмыйча);

2) сайлаучыларга тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында бирелгән бюллетеньнәр санын (сайлаучылар исемлегендәге сайлаучылар имзалары саны буенча билгеләнә);

3) тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр санын (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә);

4) вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр санын (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә; муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе) бинасында вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучылар санын, вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучылар исемлеге буенча тикшерелә);

5) участок комиссиясе тарафыннан сайлаучыларга сайлау участогында бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары санын;

6) муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе) тарафыннан сайлаучыларга бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары санын;

7) сайлау участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән сайлаучылар санын.”;

д) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәргәндә, әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән күрсәткечләр кертелгәннән соң, шушы күрсәткечләрне керткән комиссия әгъзасы сайлаучылар исемлегенең һәр битенә имза сала, аннан соң бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, игълан итә һәм участок комиссиясе рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена һәм тавышларны санаганда шунда булган затларга хәбәр итә. Әлеге статьяның 5 өлеше нигезендә билгеләнгән күрсәткечләр суммасы буларак билгеләнә торган йомгаклау күрсәткечләрен участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре игълан итә, сайлаучылар исемлегенең соңгы битенә кертә, аларны үз имзасы һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклый. Игълан ителгән күрсәткечләр – тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына, ә тавышларны санауның техник чаралары кулланылган очракта, беркетмәнең зурайтылган рәвешенең түбәндәге тиешле юлларына гына кертелә:

1) 1 юлга – тавыш бирү тәмамланган вакытка сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар саны;

2) 3 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

3) 4 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны.

Шуннан соң күзәтүчеләр һәм әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар сайлаучылар исемлеге белән танышырга, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга хокуклы.";

е) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

"$6^1$. Җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәргәндә, әлеге статьяның $5^1$ өлешендә күрсәтелгән күрсәткечләр кертелгәннән соң, шушы күрсәткечләрне керткән комиссия әгъзасы сайлаучылар исемлегенең һәр битенә имза сала, аннан соң бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, игълан итә һәм участок комиссиясе рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена һәм тавышларны санаганда шунда булган затларга хәбәр итә. Әлеге статьяның $5^1$ өлеше нигезендә билгеләнгән күрсәткечләр суммасы буларак билгеләнә торган йомгаклау күрсәткечләрен участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре игълан итә, сайлаучылар исемлегенең соңгы битенә кертә, аларны үз имзасы һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклый. Игълан ителгән күрсәткечләр – тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына, ә тавышларны санауның техник чаралары кулланылган очракта, беркетмәнең зурайтылган рәвешенең түбәндәге тиешле юлларына гына кертелә:

1) 1 юлга – тавыш бирү тәмамланган вакытка сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар саны;

2) 2а һәм 2б юлларына – вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

3) 3 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

4) 4 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

5) 9а юлына – участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

6) 9б юлына – тавыш бирү көненә кадәр участок комиссиясе тарафыннан сайлаучыларга сайлау участогында бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

7) 9в юлына – сайлау участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән сайлаучылар саны;

8) 9г юлына – сайлау участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9) 9д юлына – муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе) тарафыннан сайлаучыларга бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.

Әлеге гамәлләрне башкарганнан соң, түбәндәге контроль чагыштырма тикшерелә: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү

таныклыклары саны тавыш бирү көненә кадәр участок комиссиясе тарафыннан сайлаучыларга сайлау участогында бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм сайлау участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны суммасына тигез булырга тиеш. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлмәсә, участок комиссиясе сайлаучылар исемлегенә кертелгән күрсәткечләрне һәм юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын өстәмә санау турында карар кабул итә. Әгәр өстәмә санау нәтиҗәсендә әлеге контроль чагыштырма яңадан үтәлмәсә, участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушымта итеп бирелә торган тиешле карарны кабул итә һәм аерма турындагы күрсәткечләрне тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 9е юлына кертә. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлсә, 9е юлында “0” саны куела.

Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 9а, 9б, 9в, 9г, 9д, һәм 9е юлларына күрсәткечләр бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган очракта кертелә.

Шуннан соң күзәтүчеләр һәм әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар сайлаучылар исемлеге белән танышырга, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга хокуклы.”;

ж) 7 өлештә “5 өлешендә” сүзләрен “5 һәм $5^1$ өлешләрендә” сүзләренә алмаштырырга;

з) 13 өлештә “8 юлына” сүзләрен “6 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

и) $16^1$ өлештә “территориаль комиссия,” сүзләрен төшереп калдырырга, “округ сайлау комиссиясе” сүзләрен “округ комиссиясе” сүзләренә алмаштырырга;

к) 17 өлештә “10 юлына” сүзләрен “8 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

л) 18 өлештә “14 юлына” сүзләрен “12 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

м) 19 өлештә “11 юлына” сүзләрен “9 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

н) 20 өлештә “9 юлына” сүзләрен “7 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

о) 22 өлештә “6 өлеше нигезендә” сүзләрен “$6^1$ өлеше нигезендә” сүзләренә, “12 һәм 13 юлларына” сүзләрен “10 һәм 11 юлларына” сүзләренә, “12 һәм 13 юлларында” сүзләрен “10 һәм 11 юлларында” сүзләренә алмаштырырга;

п) $23^1$ өлештә:

3 пунктта “1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 юлларына” сүзләрен “1, 2, 2а, 2б, 3, 4, 5 юлларына” сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта “8, 9, 10, 11, 14 һәм алдагы юлларына” сүзләрен “6, 7, 8, 9, 12 һәм алдагы юлларына” сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта “12 һәм 13 юлларына” сүзләрен “10 һәм 11 юлларына” сүзләренә алмаштырырга;

р) 24 өлештә “10, 11, 14 һәм алдагы юлларының” сүзләрен “8, 9, 12 һәм алдагы юлларының” сүзләренә алмаштырырга;

с) 31 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“31. “Россия Федерациясендә гражданнарның сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә участок комиссияләре сайлауларда тавыш биргәндә Россия

Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча яисә аның йөкләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча тавыш бирүнең стационар әрҗәләре урынына тавышларны санауның техник чараларыннан яисә электрон тавыш бирү комплексларыннан файдаланалар. Төрле дәрәҗәдәге сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта барлык дәрәҗәдәге бөтен сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавышларны санаганда тавышларны санауның техник чараларыннан, электрон тавыш бирү комплексларыннан файдалану мәҗбүри. Тавышларны санауның техник чаралары һәм электрон тавыш бирү комплекслары файдаланыла торган сайлау участоклары исемлеген Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның йөкләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгели.

Тавышларны санауның техник чараларыннан файдаланганда участок комиссиясе тарафыннан тавышларны санау әлеге статьяның 23[1] өлеше нигезендә башкарыла. Бер территориаль комиссия эшли торган территория чикләрендә мондый техник чаралар файдаланылган, жирәбә салып билгеләнә торган кимендә 5 процент сайлау участогында (әмма кимендә өч сайлау участогында) сайлаучыларның тавышларын контроль санауны турыдан-туры участок комиссияләренең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия әгъзалары башкара (тавышларны кулдан санау). Бу очракта жирәбә салуны тавыш бирү вакыты беткәннән соң ярты сәгать эчендә югарырак сайлау комиссиясе үткәрә, ә жирәбә салу нәтиҗәләре кичекмәстән һәр участок комиссиясенә хәбәр ителә. “Россия Федерациясендә гражданнарның сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә төрле дәрәҗәдәге сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта тавышларны контроль санауны үткәрү тәртибен, үткәрелә торган сайлауларның, референдумның дәрәҗәсенә карап, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе йә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгели.

Тавышларны контроль (кулдан) санау үткәрелү ихтималы турында тавышларны санауның техник чаралары файдаланылган сайлау участогында тавыш бирүгә йомгак ясалганда булган барлык затларга да хәбәр ителергә тиеш. Тавышларны кулдан санау күзәтүчеләр, әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар булганда башкарыла. Жирәбә салып билгеләнгән сайлау участокларында тавышларны кулдан санау әлеге статьяның 9 – 12, 14 – 16, 17 – 19, 21 – 23 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә башкарыла. Тавышларны кулдан санау йомгаклары буенча йә тавыш бирү йомгаклары турында яңа беркетмә төзелә (тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсенең 8, 9, 12 нче юлларының һәм алардан соңгы юлларның берәрсендә генә булса да тавышларны кулдан санау күрсәткечләре белән тавышларны санауның техник чараларыннан файдаланып алынган күрсәткечләр арасындагы аерманың бер проценттан күбрәк (ул тавышларны кулдан санау күрсәткечләре белән тавышларны санауның техник чараларыннан файдаланып алынган күрсәткечләр арасындагы аерманы күбрәк сандагы тавышларга бүлеп билгеләнә), әмма кимендә өч берәмлек булуы ачыкланса), аңа “Кабат” дигән тамга куела һәм участок комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беренчел беркетмәсе белән бергә югарырак сайлау

комиссиясенә җибәрелә, йә тавышларны кабат санау барышында алынган күрсәткечләрнең беренчел күрсәткечләр белән туры килүе турында акт төзелә, ул участок комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсе белән бергә югарырак сайлау комиссиясенә җибәрелә. Тавышларны контроль (кулдан) санау үткәрү өчен жирәбә салып билгеләнгән сайлау участогының участок комиссиясе рәисе тавышларны контроль (кулдан) санау нәтиҗәләре билгеләнгәннән соң ук алынган нәтиҗәләр турында югарырак сайлау комиссиясенә хәбәр итә.

Тавышларны контроль (кулдан) санау үткәрү өчен сайлау участокларын жирәбә салып билгеләгән югарырак сайлау комиссиясе күрсәтелгән сайлау участокларының участок комиссияләре рәисләреннән тавышларны контроль (кулдан) санау нәтиҗәләре турында белешмәләр алганнан соң, әгәр беркетмәнең 8, 9, 12 нче юлларындагы һәм алардан соңгы юллардагы тавышларны сануның техник чараларыннан файдаланганда һәм тавышларны кулдан санаганда алынган күрсәткечләр туры килмәү сәбәпле тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә тавышларны контроль санау нәтиҗәсендә жирәбә салып билгеләнгән сайлау участокларының берсендә генә булса да кабат төзелсә, кичекмәстән тиешле карар, шул исәптән тавышларны кулдан санау үткәрелмәгән һәм тиешле территориядә урнашкан барлык сайлау участокларында тавышларны кулдан сануны үткәрү турында карар кабул итә.

Тавышларны сануның техник чаралары файдаланылган сайлау участокларының участок комиссияләре, тавышларны кулдан санаганда тавыш бирү йомгаклары чыгарылганнан соң һәм тавыш бирү йомгаклары турында кабат төзелгән беркетмәләр йә күрсәткечләрнең туры килүе турында актлар әлеге статьяның 29 өлешендә каралган тәртиптә имзаланганнан соң, беркетмәләрне югарырак комиссиягә җибәрәләр.

т) түбәндәге эчтәлекле $31^1$ өлеш өстәргә:

“$31^1$. Тавышларны сануның техник чараларын файдаланганда тавышларны санау күрсәткечләрен, тавыш биргән сайлаучыларның гомуми исәбе турындагы мәгълүматлардан тыш, сайлау участогында тавыш бирү тәгәлләнгәнче фаш итү тыела.”;

у) түбәндәге эчтәлекле $31^2$ өлеш өстәргә:

“$31^2$. Участок комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсендәге күрсәткечләр, шул исәптән тавышларны сануның техник чараларыннан, электрон тавыш бирү комплексларыннан файдаланып алынганнары, тиешле җиһаз булганда, “Сайлаулар” ДАС файдаланып, югарырак комиссиягә тапшырыла.”;

ф) 33 өлештә “1 – 13 юлларында” сүзләрен “1 – 11 юлларында” сүзләренә алмаштырырга, “1 – 13 юлларына” сүзләрен “1 – 11 юлларына” сүзләренә алмаштырырга, “14 юлына” сүзләрен “12 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

21) 80 статьяның 13 өлешендә “1 – 13 юлларына (законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирү каралган очракта 11а – 11е юлларына)” сүзләрен “1 – 11 юлларына (законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча

тавыш бирү каралган очракта 9а – 9е юлларына)” сүзләренә алмаштырырга, “14 юлын” сүзләрен “12 юлын” сүзләренә алмаштырырга;

22) 114 статьяга түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

“$5^1$. Күпмандатлы сайлау округы буенча сайлаулар үткәргәндә сайлау бюллетененә кертелгән башка кандидатларга караганда иң күп сайлаучылар тавышын җыйган кандидатлар сайланган депутатлар дип санала, аларның саны күпмандатлы сайлау округында билгеләнгән мандатлар санына тигез була.”;

23) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2 нче кушымта

**ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘЛӘРГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАСЫ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘЛӘРНЕҢ ӘЛЕГЕ КОДЕКСНЫҢ 78 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)**

1) 1 күбрәк яисә тигез 3 + 4 (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәрелгән очракта);

2) 1 күбрәк яисә тигез 2а + 3 + 4 (җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәрелгән очракта);

3) 2 тигез 3 + 4 + 5 + 10 – 11 (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәрелгән очракта);

4) 2 тигез 2а – 2б + 3 + 4 + 5 + 10 – 11 (җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәрелгән очракта);

5) 6 + 7 тигез 8 + 9;

6) 9 тигез 12 + беркетмәнең барлык калган юллары (күпмандатлы сайлау округлары төзелә торган очраклардан тыш);

7) 9а тигез 9б + 9г + 9е (әгәр сайлаулар үткәрелгәндә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларыннан файдалану каралган булса).

Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына депутатлар сайлауларны үткәргәндә күпмандатлы сайлау округлары төзелсә, әлеге кушымтаның 6 пунктында каралган контроль чагыштырма урынына түбәндәге контроль чагыштырмалар тикшерелә:

8) 9 кимрәк яисә тигез 12 + беркетмәнең барлык калган юллары;

9) 9 x M күбрәк яисә тигез 12 + беркетмәнең барлык калган юллары, монда M – сайлау округында бүленергә тиешле мандатлар саны (округларында мандатлар саны тигез булган күпмандатлы сайлау округлары өчен, һәрбер сайлаучының мандатлар санына тигез тавышлар саны булу шарты белән);

10) 9 x B күбрәк яисә тигез 12 + беркетмәнең барлык калган юллары, монда B – мандатлар саны иң аз булган сайлау округында бүленергә тиешле мандатлар саны йә, законда һәрбер сайлаучының бер тавышка ия булуы каралган булса,

“1” күрсәткече (округларында мандатлар саны төрле булган күпмандатлы сайлау округлары өчен йә округларында мандатлар саны тигез булган күпмандатлы сайлау округлары өчен, һәрбер сайлаучы бер тавышка ия булу шарты белән);

11) 9 күбрәк яисә I тигез, монда I – сайлаучыларның һәрбер кандидат өчен бирелгән тавышлары.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы референдумы турында” 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяда:

а) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7. Референдумда катнашучы имза кәгазендә үз имзасын куя һәм аны кую датасын яза, шулай ук үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын (тавыш бирү көненә 18 яшендә булса, өстәмә рәвештә туган числосын һәм аен), яшәү урыны адресын, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен, номерын күрсәтә. Яшәү урыны адресында Федераль законның 2 статьясындагы 5 пунктчасында билгеләнгән реквизитларның кайберләре (Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункт, урам исеме, йорт һәм фатир номеры), әгәр аларны күрсәтмәү, референдумда катнашучының яшәү урынының чынбарлыктагы үзенчәлекләрен исәпкә алып, бер мәгънәдә генә аңлауга комачаулык тудырмаса, күрсәтелмәскә мөмкин. Имза кәгазендә үзенең имзасын куя торган һәм аны кую датасын яза торган референдумда катнашучы турында белешмәләр референдум үткәрү инициативасын хуплап имзалар җыючы зат тарафыннан референдумда катнашучы үтенече буенча имза кәгазенә кертелергә мөмкин. Әлеге белешмәләр бары тик кулдан гына языла, бу чакта карандашлар куллану рөхсәт ителми. Имзасын һәм аны кую датасын референдумда катнашучы шәхсән үз кулы белән куя. Әгәр референдумда катнашучы инвалид булса һәм шул сәбәпле имза кәгазенә мөстәкыйль үз имзасын куя алмаса һәм аны кую датасын яза алмаса, ул бу гамәлләрне башкару өчен комиссия әгъзасы, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле булмаган референдумдагы башка катнашучының ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Бу очракта референдумда катнашучыга ярдәм итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе һәм номеры имза куела торган графада күрсәтелергә тиеш. Референдумда катнашучы, референдум үткәрү буенча бер үк инициативаны хуплап, бер генә мәртәбә имза куярга хокуклы.”;

б) 8 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Яшәү урыны адресында Федераль законның 2 статьясындагы 5 пунктчасында билгеләнгән реквизитларның кайберләре (Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункт, урам исеме, йорт һәм фатир номеры), әгәр аларны күрсәтмәү, референдумда

катнашучыларның имзаларын җыюны гамәлгә ашыручы затның яшәү урынының чынбарлыктагы үзенчәлекләрен исәпкә алып, аны бер мәгънәдә генә аңлауга комачаулык тудырмаса, күрсәтелмәскә мөмкин.";

в) 9 пунктта "референдум үткәрү буенча" сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 11 пунктта "референдум үткәрү буенча" сүзләрен төшереп калдырырга;

2) $13^2$ статьяның 7 пунктындагы "з" пунктчасында "референдум үткәрү буенча" сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 16 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:

"$11^1$. Референдумда катнашучы инвалидларның, кресло-коляскаларда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп, тиешле территориядәге саны турында инвалидлык төркемнәре буенча һәм организмның күрү (сукырлар, начар күрүчеләр), ишетү (ишетмәүчеләр), терәк-хәрәкәт аппараты (аяк-кул функцияләре нык бозылган затлар) функцияләре көчле бозылу буенча белешмәләр, федераль инвалидлар реестры белешмәләренә нигезләнеп, һәр елның 1 гыйнварына һәм 1 июленә торышы буенча тиешле ай эчендә Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан түбәндәгеләргә тапшырыла:

а) Татарстан Республикасы буенча – Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә;

б) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре буенча – Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә.";

б) түбәндәге эчтәлекле $11^2$ пункт өстәргә:

"$11^2$. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инвалидларны социаль яклау һәм аларга социаль ярдәм өлкәсендәге органы Федераль закон нигезендә референдум комиссияләренә, организм функцияләренең көчле бозылуын исәпкә алып, инвалид булган Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу хокукын тәэмин итү эшендә, шулай ук алар арасында төзелә торган килешү нигезендә әлеге гражданнарга кирәкле ярдәм күрсәтүдә булышырга тиеш.";

4) 17 статьяның "$д^1$" пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

5) 19 статьяда:

а) "$д^1$" пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

б) "ж" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"ж) тавыш бирү көнендә референдум участогында тавыш бирүне оештыра;";

6) 22 статьяда:

а) 1 пунктта "бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары," сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 пунктта ", шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә" сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 4 пунктның беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Референдум үткәрелгәндә күзәтүчене инициатив төркем, республика яисә федераль дәрәҗәдә оешкан һәм теркәлгән булырга тиешле иҗтимагый берләшмә билгеләп куярга мөмкин.”;

г) 6 пунктта “алар вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргәндә,” сүзләрен төшереп калдырырга;

д) $7^1$ пунктта “(вакытыннан алда тавыш бирү)” сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 8 пунктның өченче җөмләсендә “(вакытыннан алда тавыш бирү)” сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 9 пунктта:

“а” пунктчасында “бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестры, комиссиядәге бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,” сүзләрен төшереп калдырырга;

“б” пунктчасында “, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә” сүзләрен төшереп калдырырга;

з) $11^1$ пунктында “, вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә” сүзләрен төшереп калдырырга;

и) $11^2$ пунктында “(вакытыннан алда тавыш бирү)” сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 26 статьяда:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Төгәл билгеле референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә Россия Федерациясе гражданын кертү өчен аның яшәү урыны шушы участок территориясендә булу факты, ә Федераль законда, башка федераль законда, әлеге Законда каралган очракларда – гражданның шул участок территориясендә булу (вакытлыча булу, килеп тору) факты (гражданның референдумда катнашу хокукы булганда) нигез булып тора. Гражданның яшәү йә булу (вакытлыча булу) урынының билгеле бер референдум участогы территориясендә булуы факты Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны буенча һәм булу урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәп исәпкә алу органнары тарафыннан, ә Федераль законда, башка федераль законда, әлеге Законда каралган очракларда – шуңа вәкаләтле башка органнар, оешмалар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан билгеләнә. Россия Федерациясе гражданын билгеле бер референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертү әлеге Законның 50 статьясындагы 15 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

б) 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 14 пунктта:

бишенче җөмләдә “, шулай ук референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән очракта гына” сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче җөмләдә “, ә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгәндә – бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы биргән комиссия әгъзасының имзасы” сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“15. Тавыш бирү көнендә хастаханәдә яисә шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне сак астында тоту урыннарында булырга тиешле референдумда катнашучылар, шулай ук хәрби часть урнашкан урыннан читтәге хәрби хезмәткәрләргә караган референдумда катнашучылар, тавыш бирү көненә кадәрге көннең җирле вакыт буенча 14 сәгатеннән дә соңга калмыйча, участок комиссиясенә тапшырылган шәхсән язылган гаризасы нигезендә аларның вакытлыча булу урыны буенча референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелергә мөмкин. Референдумда катнашучыны аның вакытлыча булу урыны буенча референдум участогында катнашучылар исемлегенә кертү турында мәгълүмат әлеге референдумда катнашучының яшәү урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдум участогының участок комиссиясенә, шул исәптән “Сайлаулар” ДАС кулланып, тапшырыла. Участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле юлында, референдум участогының номерын күрсәтеп, “__ номерлы референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелде“ дигән тамга куя.”;

8) 37 статьяның 3 пунктында “референдум үткәрү буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 40 статьяның 3 пунктында “әлеге материалларны әзерләгән һәм аларга заказ биргән оешманың (затның) урнашкан урыны турында (яшәү урынының адресы турында) белешмәләр” сүзләрен “әлеге материалларны әзерләгән һәм аларга заказ биргән юридик затның, индивидуаль эшкуарның адресы (физик затның яшәү урыны адресы) турында белешмәләр” сүзләренә алмаштырырга;

10) 43 статьяның 9 пунктында “бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын,” сүзләрен төшереп калдырырга;

11) 44 статьяның 2 пунктындагы “а” пунктчасында “референдум уздыру буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;

12) $47^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

13) 49 статьяның 9 пунктында:

“(шул исәптән вакытыннан алда тавыш бирергә)” сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: “Үзенең килеп тору урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә кертү турында әлеге Законның 50 статьясындагы 15 пунктында билгеләнгән тәртиптә гариза биргән референдумда катнашучылар күпләп күчелгән референдум участогында, шулай ук 500 дән ким референдумда катнашучы теркәлгән һәм бюллетеньнәрне эшкәртүнең программа-техник комплекслары кулланыла торган референдум участогында бюллетеньнәрнең исәбе тиешле комиссия карары белән арттырылырга мөмкин.”;

14) 50 статьяда:

а) 2 пунктта “вакытыннан алда һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 пунктка “, әлеге референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның саны турында, башка референдум участогында үзенең килеп тору урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә кертү турында гариза бирелү сәбәпле референдумда катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырылган референдумда катнашучыларның саны хакында, шулай ук шул референдум участогында үзенең килеп тору урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә кертү турында гариза биргән референдумда катнашучыларның саны турында мәгълүмат бирә” сүзләрен өстәргә;

в) 5 пунктта “, әгәр референдумда катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирсә, – шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы күрсәтелә” сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 6 пунктта дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

д) 10 пунктта “референдум үткәрү буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 12 пунктта “һәм мондый хокук бозу факты суд тәртибендә билгеләнсә” сүзләрен төшереп калдырырга, түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: “Участок комиссиясе әгъзасын әлеге комиссия эшендә катнашудан читләштерү, күзәтүчене яисә башка затны тавыш бирү бүлмәсеннән чыгару турында карар участок комиссиясенең урнашу урыны буенча суд тарафыннан кабул ителә.”;

ж) түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

“15. Референдум үткәрелгәндә тавыш бирү көнендә үзенең яшәү урыныннан читтә булачак тиешле референдумда катнашучы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә референдум комиссиясенә үзенең килеп тору урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә кертү турында гариза (алга таба әлеге пунктта – гариза) бирергә хокуклы. Гариза референдумда катнашучы тарафыннан бары тик шәхсән үзе паспортын (паспортны алмаштыру чорында – вакытлыча шәхес таныклыгын) күрсәткәч кенә бирелә ала. Гариза биргән референдумда катнашучы үзенең яшәү урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырыла. Гариза биргән референдумда катнашучы үзенең килеп тору урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә бары тик бер референдум участогында гына кертелә ала. Гариза биргән һәм тавыш бирү көнендә үзенең яшәү урыны буенча референдум участогына килгән референдумда катнашучы референдумда катнашучылар исемлегенә бары тик участок комиссиясе карары буенча гына һәм бары тик ул үзенең килеп тору урыны буенча референдум участогында тавыш бирмәвен күрсәтә торган факт билгеләнгәннән соң гына кертелергә мөмкин. Референдумда катнашучы үзенең яшәү урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән очракта, ул үзенең килеп тору урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән булу хокукын югалта.”;

15) $50^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

16) 52 статьяда:

а) 2 пунктның “д” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“д) беркетмә юллары түбәндәге тәртиптә:

1 юл: тавыш бирү тәмамланган мизгелгә исемлеккә кертелгән референдумда катнашучылар саны;

2 юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәр саны;

3 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

4 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

5 юл: юкка чыгарылган бюллетеньнәр саны;

6 юл: тавыш бирү өчен күчерелмә әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

7 юл: тавыш бирү өчен стационар әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

8 юл: гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны;

9 юл: гамәлгә яраклы бюллетеньнәр саны;

10 юл: юкка чыккан бюллетеньнәр саны;

11 юл: алганда исәпкә алынмаган бюллетеньнәр саны;

12 юл һәм аннан соңгы юллар: бюллетеньнәрдәге “Әйе” һәм “Юк” (“Хуплыйм” һәм “Каршы”) позицияләре буенча референдумда катнашучылар тавышлары саны;”;

б) $2^1$ пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 3 пунктта “2 һәм $2^1$ пунктларында” сүзләрен “2 пунктында” сүзләренә алмаштырырга;

17) 53 статьяда:

а) 3 пунктта “7 юлына” сүзләрен “5 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктта “(территория комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргәннәр конвертларыннан алынган бюллетеньнәр турында күрсәткечләр күрсәтелгән санга керми)” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 5 пунктта:

“а” пунктчасында “территория комиссиясе һәм участок комиссиясе тарафыннан бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирелгән референдумда катнашучылар, шулай ук” сүзләрен төшереп калдырырга;

“$в^1$” – “$в^4$” пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Әлеге статьяның 5 пунктында билгеләнгән күрсәткечләр кертелгәннән соң референдумда катнашучылар исемлегенең һәр битенә комиссиянең әлеге күрсәткечләрне керткән әгъзасы имза сала, аннары ул бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, игълан итә һәм участок комиссиясенең рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена һәм тавышларны санауда катнашучы затларга хәбәр итә. Участок комиссиясенең рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре әлеге статьяның 5 пункты нигезендә билгеләнгән күрсәткечләр суммасы буларак билгеләнүче йомгаклау күрсәткечләрен игълан итә, аларны референдумда катнашучылар исемлегенең соңгы битенә язып куя, үзенең имзасы һәм участок комиссиясе мөһере белән

таныклый. Игълан ителгән күрсәткечләр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына кертелә, ә тавышларны санаганда техник чаралар кулланылган очракта – бары тик беркетмәнең зурайтылган рәвешенең түбәндәге тиешле юлларына гына кертелә:

а) 1 юлга – тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар саны;

б) 3 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

в) 4 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны.

Шуннан соң референдумда катнашучылар исемлеге белән күзәтүчеләр һәм әлеге Законның 22 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затлар танышырга хокуклы, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган сантуның дөреслегенә инанырга хокуклы.";

д) 12 пунктта "8 юлына" сүзләрен "6 юлына" сүзләренә алмаштырырга;

е) 14[1] пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

ж) 15 пунктта "һәм әлеге Законның 50[1] статьясындагы 14 пункты" сүзләрен төшереп калдырырга, "10 юлына" сүзләрен "8 юлына" сүзләренә алмаштырырга;

з) 16 пунктта "14 юлына" сүзләрен "12 юлына" сүзләренә алмаштырырга;

и) 17 пунктта "11 юлына" сүзләрен "9 юлына" сүзләренә алмаштырырга;

к) 18 пунктта "9 юлына" сүзләрен "7 юлына" сүзләренә алмаштырырга;

л) 20 пунктта "(әлеге статьяның 6 пункты нигезендә тикшерелә торган контроль чагыштырмадан тыш)" сүзләрен төшереп калдырырга, "12 һәм 13 юлларына" сүзләрен "10 һәм 11 юлларына" сүзләренә алмаштырырга, "12 һәм 13 юлларында" сүзләрен "10 һәм 11 юлларында" сүзләренә алмаштырырга;

м) 21 пунктта "төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары," һәм ", барлык төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының гомуми саны" сүзләрен төшереп калдырырга;

н) 22 пунктта:

"в" пунктчасында "1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 юлларына" сүзләрен "1, 2, 3, 4, 5 юлларына" сүзләренә алмаштырырга;

"г" пунктчасында "8, 9, 10, 11, 14 юлларына" сүзләрен "6, 7, 8, 9, 12 юлларына" сүзләренә алмаштырырга;

"д" пунктчасында "12 һәм 13 юлларына" сүзләрен "10 һәм 11 юлларына" сүзләренә алмаштырырга;

"е" пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

о) 23 пунктта "10, 11, 14 һәм аннан соңгы юллары" сүзләрен "8, 9, 12 һәм аннан соңгы юллары" сүзләренә алмаштырырга;

п) 30 пунктта:

беренче абзацка түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: "Төрле дәрәҗәдәге сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта тавышларны сантуның техник чараларыннан яисә электрон

тавыш бирү комплексларыннан файдалану барлык дәрәҗәдәге бөтен сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавышларны санаганда мәҗбүри.”;

икенче абзацка түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: “Төрле дәрәҗәдәге сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта, тавышларны контроль санауны үткәрү тәртибен, үткәрелә торган сайлауларның, референдумның дәрәҗәсенә карап, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе йә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгели.”;

өченче абзацта “10, 11, 14 һәм аннан соңгы юлларында” сүзләрен “8, 9, 12 һәм аннан соңгы юлларында” сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта “10, 11, 14 һәм аннан соңгы юлларына” сүзләрен “8, 9, 12 һәм аннан соңгы юлларына” сүзләренә алмаштырырга;

р) 32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“32. Участок комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсендәге күрсәткечләр, шул исәптән тавышларны санауның техник чараларыннан яисә электрон тавыш бирү комплексларыннан файдаланып алынганнары, тиешле җиһаз булганда, “Сайлаулар” ДАС файдаланып, югарырак комиссиягә тапшырыла.”;

с) 35 пунктта “беркетмәнең 1 – 13 юлларында” сүзләрен “беркетмәнең 1 – 11 юлларында” сүзләренә алмаштырырга, “беркетмәнең 1 – 13 юлларына” сүзләрен “беркетмәнең 1 – 11 юлларына” сүзләренә алмаштырырга, “14 юлына” сүзләрен “12 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

18) 54 статьяда:

а) 3 пунктның икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

б) 8 пунктта “1 – 13 юлларына (әгәр законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган булса, 11а – 11е юлларына)” сүзләрен “1 – 11 юлларына” сүзләренә алмаштырырга, “14 юлына” сүзләрен “12 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

19) 55 статьяда:

а) 1 пунктның җиденче һәм сигезенче абзацларын төшереп калдырырга;

б) 4 пунктта “, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын” сүзләрен төшереп калдырырга;

20) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2 нче кушымта

**ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ НИСБӘТЕ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘНЕҢ ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 52 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)**

1) 1 күбрәк яисә тигез 3 + 4;
2) 2 тигез 3 + 4 + 5 + 10 – 11;
3) 6 + 7 тигез 8 + 9;
4) 9 тигез 12 + беркетмәнең аннан соңгы бөтен юллары.”.

**3 статья**

“Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяда:
а) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“7. Референдумда катнашучы имза кәгазендә үз имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә, шулай ук үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын (тавыш бирү көненә 18 яшендә булса, өстәмә рәвештә туган числосын һәм аен), яшәү урыны адресын, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен, номерын күрсәтә. Яшәү урыны адресында “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 2 статьясындагы 5 пунктчасында билгеләнгән реквизитларның кайберләре (Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункт, урам исеме, йорт һәм фатир номеры), әгәр аларны күрсәтмәү, референдумда катнашучының яшәү урынының чынбарлыктагы үзенчәлекләрен исәпкә алып, бер мәгънәдә генә аңлауга комачаулык тудырмаса, күрсәтелмәскә мөмкин. Имза кәгазендә үзенең имзасын куя торган һәм аны кую датасын күрсәтә торган референдумда катнашучы турында белешмәләр референдумда катнашучы үтенече буенча имза кәгазенә референдум үткәрү инициативасын хуплап имзалар җыючы зат тарафыннан кертелергә мөмкин. Әлеге белешмәләр бары тик кулдан гына языла, карандаш кулланылмый. Имзасын һәм аны кую датасын референдумда катнашучы шәхсән үз кулы белән яза. Әгәр референдумда катнашучы инвалид булса һәм шул сәбәпле имза кәгазенә үзе мөстәкыйль имзасын куя алмаса һәм аны кую датасын яза алмаса, ул бу гамәлләрне башкару өчен комиссия әгъзасы, инициатив төркемнең вәкиллекле вәкиле булмаган башка референдумда катнашучының ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Бу очракта референдумда катнашучыга ярдәм итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясе һәм номеры имза куела торган графада күрсәтелгән булырга тиеш. Референдумда катнашучы, референдум үткәрү буенча бер үк инициативаны хуплап, бер генә мәртәбә имза куярга хокуклы.”;
б) 8 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Яшәү урыны адресында “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда

катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 2 статьясындагы 5 пунктчасында билгеләнгән реквизитларның кайберләре (Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункт, урам исеме, йорт һәм фатир номеры), әгәр аларны күрсәтмәү, референдумда катнашучыларның имзаларын җыючы затның яшәү урынының чынбарлыктагы үзенчәлекләрен исәпкә алып, бер мәгънәдә генә аңлауга комачаулык тудырмаса, күрсәтелмәскә мөмкин.”;

в) $8^{1}$ пунктта “референдум уздыру буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 9 пунктта “референдум уздыру буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 15 статьяның 8 пунктындагы “з” пунктчасында “референдум уздыру буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 19 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $11^{1}$ пункт өстәргә:

“$11^{1}$. Референдумда катнашучы инвалидларның, кресло-коляскаларда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп, референдумда катнашучыларның тиешле территориядәге исәбе турында инвалидлык төркемнәре буенча һәм организмның күрү (сукырлар, начар күрүчеләр), ишетү (ишетмәүчеләр), терәк-хәрәкәт аппараты (аяк-кул функцияләре нык бозылган затлар) функцияләре көчле бозылу буенча белешмәләр “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан федераль инвалидлар реестры белешмәләре нигезендә тиешле ай эчендә һәр елның 1 гыйнварына һәм 1 июленә торышы буенча түбәндәгеләргә тапшырыла:

а) Татарстан Республикасы буенча – Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә;

б) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре буенча – Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә.”;

б) түбәндәге эчтәлекле $11^{2}$ пункт өстәргә:

“$11^{2}$. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инвалидларны социаль яклау һәм аларга социаль ярдәм өлкәсендәге органы “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә референдум комиссияләренә, организм функцияләренең көчле бозылуын исәпкә алып, инвалид булган Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу хокукын тәэмин итү эшендә, шулай ук алар арасында төзелә торган килешү нигезендә әлеге гражданнарга кирәкле ярдәм күрсәтүдә булышырга тиеш.”;

4) 24 статьяның 4 пунктындагы беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Референдум уздырганда күзәтүчене инициатив төркем, референдум дәрәҗәсенә туры килә торган дәрәҗәдә яисә югарырак дәрәҗәдә төзелергә һәм теркәлергә тиешле иҗтимагый берләшмә билгеләп куя ала.”;

5) 27 статьяда:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Референдумның конкрет участогында Россия Федерациясе гражданын референдумда катнашучылар исемлегенә кертү өчен аның яшәү урынының шушы участок территориясендә булу факты, ә “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, башка федераль законда, әлеге Законда каралган очракларда – гражданның әлеге участок территориясендә булу (вакытлыча булу) факты (гражданның референдумда катнашу хокукы булганда) йә гражданның бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы булуы нигез булып тора. Гражданның яшәү йә булу (вакытлыча булу) урынының референдумның аерым бер участогы территориясендә булу факты Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны һәм булу урыны буенча теркәп исәпкә алу органнары тарафыннан, ә “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, башка федераль законда, әлеге Законда каралган очракларда – шуны эшләргә вәкаләтле органнар, оешмалар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан билгеләнә.”;

б) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“16. Вакытлыча булу урыннарындагы, өзлексез циклда эшләүче предприятиеләрдә һәм эш (смена) дәвамлылыгын киметү мөмкин булмаган аерым төр эшләрдә эшләүче референдумда катнашучылар, шулай ук хәрби часть урнашкан урыннан читтәге хәрби хезмәткәрләр арасыннан булган референдумда катнашучылар, участок комиссиясе карары белән, тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча участок комиссиясенә шәхсән бирелгән язмача гаризалары нигезендә аларның вакытлыча булу урыны буенча референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелергә мөмкин. Референдумда катнашучыны аның вакытлыча булу урыны буенча референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертү турында мәгълүмат, шул исәптән “Сайлаулар” ДАС кулланып, әлеге референдумда катнашучының яшәү урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдум участогының участок комиссиясенә тапшырыла. Участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле юлында, референдум участогының номерын күрсәтеп, “__ номерлы референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелде” дигән тамга куя.”;

6) 39 статьяның 3 пунктында “референдум үткәрү буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 42 статьяның 3 пунктында “әлеге материалларны әзерләгән һәм аларга заказ биргән оешманың (затның) урнашкан урыны турында (яшәү урынының адресы турында) белешмәләр” сүзләрен “әлеге материалларны әзерләгән һәм аларга заказ

биргән юридик затның, индивидуаль эшкуарның адресы (физик затның яшәү урыны адресы) турында белешмәләр” сүзләренә алмаштырырга;

8) 45 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: “Күрсәтелгән чыгымнарны финанслау тиешле бюджет чыгымнарын бүлү турында расланган бюджет язмасы нигезендә, ләкин референдумны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көннән алып ун көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.”;

9) 46 статьяның 2 пунктындагы “а” пунктчасында “референдум уздыру буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;

10) $49^1$ статьяның 7 пунктында “стационар дәвалау-профилактикалау учреждениесе администрациясе (әгәр референдумда катнашучы шул учреждениедә дәвалана торган булса)” сүзләреннән соң “ – халыкны социаль яклау органы җитәкчесе тарафыннан (әгәр референдумда катнашучы инвалид булса),” сүзләрен өстәргә;

11) 51 статьяның 8 пунктына түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче җөмлә өстәргә: “Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары булган референдумда катнашучылар күпләп көтелә торган референдум участогында, шулай ук референдумда катнашучылар 500 дән ким теркәлгән һәм бюллетеньнәрне эшкәртүнең программа-техник комплекслары кулланыла торган референдум участогында бюллетеньнәрнең саны тиешле комиссия карары белән арттырылырга мөмкин.”;

12) 52 статьяда:

а) 10 пунктта “референдум үткәрү буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 12 пунктта “һәм мондый хокук бозу факты суд тәртибендә билгеләнсә,” сүзләрен төшереп калдырырга, түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: “Участок комиссиясе әгъзасын әлеге комиссия эшендә катнашудан читләштерү, күзәтүчене яисә башка затны тавыш бирү бүлмәсеннән чыгару турында карар участок комиссиясенең урнашу урыны буенча суд тарафыннан кабул ителә.”.

13) 55 статьяда:

а) 30 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“30. “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә участок комиссияләре референдумда тавыш биргәндә Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча яисә аның йөкләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча тавыш бирүнең стационар әрҗәләре урынына тавышларны санауның техник чараларыннан яисә электрон тавыш бирү комплексларыннан файдаланалар. Төрле дәрәҗәдәге сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта барлык дәрәҗәдәге бөтен сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда

тавышларны санаганда тавышларны санауның техник чараларыннан, электрон тавыш бирү комплексларыннан файдалану мәҗбүри. Тавышларны санауның техник чаралары һәм электрон тавыш бирү комплекслары файдаланыла торган референдум участоклары исемлеген Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның йөкләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгели.

Тавышларны санауның техник чараларыннан файдаланганда, участок комиссиясе тарафыннан тавышларны санау әлеге статьяның 22 пункты нигезендә башкарыла. Бер территориаль комиссия эшли торган территория чикләрендә мондый техник чаралар файдаланылган, жирәбә салып билгеләнә торган референдум участокларының кимендә 5 процентында (әмма кимендә өч референдум участогында) референдумда катнашучыларның тавышларын контроль санауны (тавышларны кулдан санау) турыдан-туры участок комиссияләренең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия әгъзалары башкара. Бу очракта жирәбә салу тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң ярты сәгать эчендә югарырак комиссия тарафыннан үткәрелә, ә жирәбә салу нәтиҗәләре кичекмәстән һәр участок комиссиясенә хәбәр ителә. Төрле дәрәҗәдәге сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта тавышларны контроль санауны үткәрү тәртибен, үткәрелә торган сайлауларның, референдумның дәрәҗәсенә карап, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгели.

Тавышларны контроль (кулдан) санау үткәрелү ихтималы турында тавышларны санауның техник чаралары файдаланылган референдум участогында тавыш бирүнең нәтиҗәләрен чыгарганда булган барлык затларга да хәбәр ителергә тиеш. Тавышларны кулдан санау күзәтүчеләр, әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында санап кителгән башка затлар булганда башкарыла. Жирәбә салып билгеләнгән референдум участокларында тавышларны кулдан санау әлеге статьяның 8 – 11, 13, 14, 15 – 17, 19 – 21 пунктларында билгеләнгән тәртиптә башкарыла. Тавышларны кулдан санау нәтиҗәләре буенча йә тавыш бирү нәтиҗәләре турында яңа беркетмә төзелә (тавышларны кулдан санау күрсәткечләре белән тавышларны санауның техник чараларыннан файдаланып алынган күрсәткечләр арасындагы аерманың (тавышларны кулдан санау күрсәткечләре белән тавышларны санауның техник чараларыннан файдаланып алынган күрсәткечләр арасындагы аерманы күбрәк сандагы тавышларга бүлеп билгеләнә) бер проценттан күбрәк, әмма кимендә өч берәмлек булуы, тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссиясе беркетмәсенең 10, 11, 14 нче юлларында һәм алардан соңгы юлларында берәр генә булса да булуы ачыкланса), аңа “Кабат” дигән тамга куела һәм ул участок комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренчел беркетмәсе белән бергә югарырак комиссиягә җибәрелә яки тавышларны кабат санау барышында алынган күрсәткечләрнең беренчел күрсәткечләр белән туры килүе турында акт төзелә, ул участок комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмәсе белән бергә югарырак комиссиягә җибәрелә. Тавышларны контроль (кулдан) санау үткәрү өчен жирәбә салып билгеләнгән референдум участогының участок комиссиясе рәисе тавышларны контроль (кулдан) санау

нәтиҗәләре билгеләнгәннән соң ук алынган нәтиҗәләр турында югарырак комиссиягә хәбәр итә.

Тавышларны контроль (кулдан) санау үткәрү өчен референдум участокларын жирәбә салып билгеләгән югарырак комиссия күрсәтелгән референдум участокларының участок комиссияләре рәисләреннән тавышларны контроль (кулдан) санау нәтиҗәләре турында белешмәләр алганнан соң кичекмәстән тиешле карар кабул итә, шул исәптән, әгәр тавышларны контроль санау нәтиҗәсендә жирәбә салып билгеләнгән референдум участокларының берсендә генә булса да тавышларны сануның техник чараларыннан файдаланганда һәм тавышларны кулдан санаганда алынган күрсәткечләрнең беркетмәнең 10, 11, 14 нче юлларында һәм алардан соңгы юлларында туры килмәве сәбәпле тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә кабат төзелсә, тавышларны кулдан санау үткәрелмәгән һәм тиешле территориядә урнашкан барлык референдум участокларында тавышларны кулдан сануны үткәрү турында карар кабул итә.

Тавышларны сануның техник чаралары файдаланылган референдум участокларының участок комиссияләре, тавышларны кулдан санаганда тавыш бирү нәтиҗәләре билгеләнгәннән соң һәм тавыш бирү нәтиҗәләре турында кабат төзелгән беркетмәләр йә күрсәткечләрнең туры килүе турында актлар әлеге статьяның 28 пунктында каралган тәртиптә имзаланганнан соң, беркетмәләрне югарырак комиссиягә җибәрәләр.";

б) түбәндәге эчтәлекле $30^1$ өлеш өстәргә:

"$30^1$. Тавышларны сануның техник чаралары файдаланылганда тавышларны санау күрсәткечләрен, тавыш биргән референдумда катнашучыларның гомуми саны турындагы мәгълүматлардан тыш, референдум участогында тавыш бирү төгәлләнгәнче фаш итү тыела.";

в) түбәндәге эчтәлекле $30^2$ өлеш өстәргә:

"$30^2$. Участок комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмәсендәге күрсәткечләр, шул исәптән тавышларны сануның техник чараларыннан, электрон тавыш бирү комплексларыннан файдаланып алынганнары, тиешле җайланма булганда, югарырак комиссиягә "Сайлаулар" ДАС файдаланып тапшырыла.".

**4 статья**

"Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында" 2012 елның 25 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:

а) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7. Сайлаучы имза кәгазендә үз имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә, шулай ук үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын (18 яшендә булса, өстәмә рәвештә туган числосын һәм аен), яшәү урыны адресын, паспортының яисә

граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен, номерын күрсәтә. Яшәү урыны адресында “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 2 статьясындагы 5 пунктчасында билгеләнгән реквизитларның кайберләре (Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункт, урам исеме, йорт һәм фатир номеры), әгәр аларны күрсәтмәү, сайлаучының яшәү урынының чынбарлыктагы үзенчәлекләрен исәпкә алып, бер мәгънәдә генә аңлауга комачаулык тудырмаса, күрсәтелмәскә мөмкин. Имза кәгазендә үзенең имзасын куя торган һәм аны кую датасын күрсәтә торган сайлаучы турындагы белешмәләр сайлаучы үтенече буенча имза кәгазенә имзалар җыючы зат тарафыннан кертелергә мөмкин. Әлеге белешмәләр бары тик кулдан гына языла, бу чакта карандаш куллану рөхсәт ителми. Имзасын һәм аны кую датасын сайлаучы шәхсән үз кулы белән куя. Әгәр сайлаучы инвалид булса һәм шул сәбәпле имза кәгазенә мөстәкыйль үзе имзасын куя алмаса һәм аны кую датасын яза алмаса, ул бу гамәлләрне башкару өчен комиссия әгъзасы, инициатив төркемнең вәкиллекле вәкиле булмаган башка сайлаучының ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Бу очракта сайлаучыга ярдәм итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясе һәм номеры имза куела торган графада күрсәтелгән булырга тиеш. Сайлаучы, чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү буенча бер үк инициативаны хуплап, бер генә мәртәбә имза куярга хокуклы.”;

б) 8 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Яшәү урыны адресында “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 2 статьясындагы 5 пунктчасында билгеләнгән реквизитларның кайберләре (Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункт, урам исеме, йорт һәм фатир номеры), әгәр аларны күрсәтмәү, имзалар җыючы затның яшәү урынының чынбарлыктагы үзенчәлекләрен исәпкә алып, бер мәгънәдә генә аңлауга комачаулык тудырмаса, күрсәтелмәскә мөмкин.”;

2) 18 статьяның $5^1$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 20 статьяда:

а) $5^1$ пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6) тавыш бирү көнендә участокта тавыш бирүне оештыра;”;

4) 22 статьяда:

а) 1 өлештә “бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 өлештә “, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 8 өлештә “алар вакытыннан алда тавыш бирүне уздырганда,” сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 10 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Күзәтүчене инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның һәрбер бүтән төркеме, республика дәрәҗәсендә яисә федераль дәрәҗәдә төзелгән һәм теркәлгән иҗтимагый берләшмә билгеләп куя ала.”;

д) $11^1$ өлештә “(вакытыннан алда тавыш бирү)” сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 13 өлештә “(вакытыннан алда тавыш бирү)” сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 14 өлештә:

1 пунктта “бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестры, комиссиядәге бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,” сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта “, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә” сүзләрен төшереп калдырырга;

з) $16^1$ өлештә “, вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә” сүзләрен төшереп калдырырга;

и) $16^2$ өлештә “(вакытыннан алда тавыш бирү)” сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 25 статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Чакыртып алу буенча тавыш бирүнең конкрет участогында Россия Федерациясе гражданын чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү өчен аның яшәү урынының әлеге участок территориясендә булу факты, ә “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, башка федераль законда әлеге Законда каралган очракларда – гражданның әлеге участок территориясендә булу (вакытлыча булу, килеп тору) факты (гражданның чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукы булганда) нигез булып тора. Гражданның яшәү йә булу (вакытлыча булу) урынының чакыртып алу буенча тавыш бирүнең аерым бер участогы территориясендә булу факты Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны буенча һәм булу урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәп исәпкә алу органнары, ә “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, башка федераль законда, әлеге Законда каралган очракларда – шуңа вәкаләтле органнар, оешмалар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан билгеләнә. Россия Федерациясе гражданын чакыртып алу буенча тавыш бирү өчен билгеле бер участок территориясендә аны килеп тору урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү әлеге Законның 46 статьясындагы 15 өлеше нигезендә башкарыла.”;

б) 14 өлештә:

бишенче җөмләдә “, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән очракта” сүзләрен төшереп калдырырга; “гына” сүзен “генә” сүзенә алмаштырырга;

җиденче җөмләдә “, ә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгәндә – бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән комиссия әгъзасының имзасы” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 15 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“15. Тавыш бирү көнендә хастаханәләрдә, шик астындагыларны һәм гаепләнүчеләрне сак астында тоту урыннарында булган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар, шулай ук хәрби часть урнашкан урыннан читтәге хәрби хезмәткәрләр арасыннан булган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар, тавыш бирү көненә кадәрге көннең җирле вакыт белән 14 сәгатеннән дә соңга калмыйча, участок комиссиясенә шәхсән бирелгән язма гаризалары нигезендә аларның вакытлыча булу урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында участок комиссиясе карары белән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелергә мөмкин. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыны аның вакытлыча булу урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү турында мәгълүмат әлеге чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының яшәү урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән участок комиссиясенә, шул исәптән “Сайлаулар” ДАС кулланып тапшырыла. Участок комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле юлында, чакыртып алу буенча тавыш бирү участогының номерын күрсәтеп, “__ номерлы чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелде” дигән тамга куя.”;

6) 37 статьяның 4 өлешендә “әлеге материалларны әзерләгән һәм аларга заказ биргән оешманың (затның) урнашкан урыны турында (яшәү урынының адресы турында) белешмәләр” сүзләрен “әлеге материалларны әзерләгән һәм аларга заказ биргән юридик затның, индивидуаль эшкуарның адресы турында белешмәләр” сүзләренә алмаштырырга;

7) 39 статьяның 7 өлешендә “бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,” сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 43[1] статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

9) 45 статьяда:

9 өлештә:

“(шул исәптән вакытыннан алда тавыш бирү)” сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: “Үзләренең килеп тору урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү турында әлеге Законның 46 статьясындагы 15 өлешендә билгеләнгән тәртиптә гариза биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар күпләп кӧтелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар 500 дән ким теркәлгән һәм бюллетеньнәрне

эшкәртүнең программа-техник комплекслары кулланыла торган чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында бюллетеньнәрнең саны тиешле комиссия карары белән арттырылырга мөмкин.";

10) 46 статьяда:

а) 2 өлештә "вакытыннан алда һәм" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 пунктка ", әлеге чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны турында, башка чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында үзенең килеп тору урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү турында гариза бирү сәбәпле чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырылган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны хакында, шулай ук әлеге чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында үзенең килеп тору урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү турында гариза биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны турында мәгълүмат бирә" сүзләрен өстәргә;

в) 5 өлештә ", әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирсә, шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын күрсәткәч" сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 6 өлештә дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

д) 12 өлештә "һәм мондый хокук бозу факты суд тәртибендә билгеләнсә" сүзләрен төшереп калдырырга, түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: "Участок комиссиясе әгъзасын әлеге комиссия эшендә катнашудан читләштерү, күзәтүчене яисә башка затны тавыш бирү бүлмәсеннән чыгару турында карар участок комиссиясенең урнашу урыны буенча суд тарафыннан кабул ителә.";

е) түбәндәге эчтәлекле 15 өлеш өстәргә:

"15. Чакыртып алу буенча тавыш бирү үткәрелгәндә тавыш бирү көнендә үзенең яшәү урыныннан читтә булачак чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә чакыртып алу буенча тавыш бирү комиссиясенә үзенең килеп тору урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү турында гариза (алга таба әлеге өлештә – гариза) бирергә хокуклы. Гариза чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының, паспортын (паспортны алмаштыру чорында – вакытлыча шәхес таныклыгын) күрсәтеп, бары тик шәхсән үзе тарафыннан гына бирелә ала. Гариза биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы үзенең яшәү урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырыла. Гариза биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы үзенең килеп тору урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә бары тик бер чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында гына кертелә ала. Гариза биргән һәм тавыш бирү көнендә үзенең яшәү урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирү участогына килгән чакыртып алу

буенча тавыш бирүдә катнашучы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә бары тик участок комиссиясе карары буенча гына һәм бары тик ул үзенең килеп тору урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш бирмәвен дәлилли торган факт билгеләнгәннән соң гына кертелергә мөмкин. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы яшәү урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгәннән соң, ул үзенең килеп тору урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелү хокукын югалта.".

11) $46^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

12) 48 статьяда:

а) 2 өлешнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) түбәндәге эзлеклелектә беркетмә юллары:

1 юл: тавыш бирү тәмамланган мизгелгә исемлеккә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны;

2 юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәр саны;

3 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

4 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

5 юл: юкка чыгарылган бюллетеньнәр саны;

6 юл: тавыш бирү өчен күчерелмә әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

7 юл: тавыш бирү өчен стационар әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

8 юл: гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны;

9 юл: гамәлгә яраклы бюллетеньнәр саны;

10 юл: юкка чыккан бюллетеньнәр саны;

11 юл: алганда исәпкә алынмаган бюллетеньнәр саны;

12 юл һәм аннан соңгы юллар: бюллетеньнәрдәге "Чакыртып алуны хуплыйм" һәм "Чакыртып алуга каршы" позицияләре буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышлары саны";

б) $2^1$ өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) 3 өлештә "2 һәм $2^1$ өлешләрендә" сүзләрен "2 өлештә" сүзләренә алмаштырырга;

13) 49 статьяда:

а) 3 өлештә "7 юлына" сүзләрен "5 юлына" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктта "(территория комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның конвертлардан алынган бюллетеньнәре турындагы мәгълүмат күрсәтелгән санга керми)" сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 5 өлештә:

1 пунктта “ бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары территория комиссиясе һәм участок комиссиясе тарафыннан бирелгән, шулай ук” сүзләрен төшереп калдырырга;

$3^1 - 3^4$ пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән күрсәткечләр кертелгәннән соң, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең һәр битенә комиссиянең әлеге күрсәткечләрне керткән әгъзасы имза сала, ул бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, игълан итә һәм участок комиссиясе рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена һәм тавышларны санауда катнашучы затларга хәбәр итә. Участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре әлеге статьяның 5 өлеше нигезендә билгеләнгән күрсәткечләр суммасы буларак билгеләнүче йомгаклау күрсәткечләрен игълан итә, аларны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең соңгы битенә кертә, үзенең имзасы һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклый. Игълан ителгән күрсәткечләр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына кертелә, ә тавышларны санауның техник чаралары кулланылган очракта – бары тик беркетмәнең зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына гына кертелә:

1) 1 юлга – тавыш бирү тәмамланган мизгелгә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны;

2) 3 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

3) 4 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны.

Шуннан соң чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге белән күзәтүчеләр һәм әлеге Законның 22 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затлар танышырга хокуклы, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга хокуклы.”;

д) 12 өлештә “8 юлына” сүзләрен “6 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

е) $14^1$ өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

ж) 15 өлештә “һәм әлеге Законның $46^1$ статьясындагы 14 өлеше” сүзләрен төшереп калдырырга, “10 юлына” сүзләрен “8 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

з) 16 өлештә “14 юлына” сүзләрен “12 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

и) 17 өлештә “11 юлына” сүзләрен “9 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

к) 18 өлештә “9 юлына” сүзләрен “7 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

л) 20 өлештә “(әлеге статьяның 6 пункты нигезендә тикшерелә торган контроль чагыштырмаларыннан тыш)” сүзләрен төшереп калдырырга, “12 һәм 13 юлларына” сүзләрен “10 һәм 11 юлларына” сүзләренә алмаштырырга, “12 һәм 13 юлларында” сүзләрен “10 һәм 11 юлларында” сүзләренә алмаштырырга;

м) 21 өлештә “төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,” һәм “, барлык төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының гомуми саны” сүзләрен төшереп калдырырга;

н) 22 өлештә:

3 пунктта “1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 юлларына” сүзләрен “1, 2, 3, 4, 5 юлларына” сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта “8, 9, 10, 11, 14 юлларына” сүзләрен “6, 7, 8, 9, 12 юлларына” сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта “12 һәм 13 юлларына” сүзләрен “10 һәм 11 юлларына” сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

о) 23 өлештә “10, 11, 14 юлларының берсендә” сүзләрен “8, 9, 12 юлларының берсендә” сүзләренә алмаштырырга;

п) 30 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: “Төрле дәрәҗәдәге сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта барлык дәрәҗәдәге бөтен сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавышларны санаганда тавышларны санауның техник чараларыннан, электрон тавыш бирү комплексларыннан файдалану мәҗбүри.”;

р) 31 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа җөмлә өстәргә: “Төрле дәрәҗәдәге сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта тавышларны контроль санауны үткәрү тәртибен, үткәрелә торган сайлауларның, референдумның дәрәҗәсенә карап, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгели.”;

с) 32 өлештә “10, 11, 14 юлларның” сүзләрен “8, 9, 12 юлларның” сүзләренә алмаштырырга;

т) 33 өлештә “10, 11, 14 юлларында” сүзләрен “8, 9, 12 юлларында” сүзләренә алмаштырырга;

у) 36 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“36. Участок комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмәсендәге күрсәткечләр, шул исәптән тавышларны санауның техник чараларыннан, электрон тавыш бирү комплексларыннан файдаланып алынганнары, тиешле җайланма булганда, югарырак комиссиягә “Сайлаулар” ДАС файдаланып тапшырыла.”;

ф) 38 өлештә “беркетмәнең 1 – 13 юлларында” сүзләрен “беркетмәнең 1 – 11 юлларында” сүзләренә алмаштырырга, “беркетмәнең 1 – 13 юлларына” сүзләрен “беркетмәнең 1 – 11 юлларына” сүзләренә алмаштырырга, “14 юлына” сүзләрен “12 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

14) 50 статьяда:

а) 8 өлешнең икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

б) 13 өлештә “1 – 13 юлларына (әгәр законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган булса, 11а – 11е юлларына)” сүзләрен “1 – 11 юлларына” сүзләренә алмаштырырга, “14 юлына” сүзләрен “12 юлына” сүзләренә алмаштырырга;

15) 51 статьяда:

а) $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) 9 өлештә “, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын” сүзләрен төшереп калдырырга;

16) $1^1$ нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

17) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Президентын
чакыртып алу тәртибе турында”
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘГӘ
КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ НИСБӘТЕ
(САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘНЕҢ ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 48 СТАТЬЯСЫ
НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

1) 1 күбрәк яисә тигез 3 + 4;
2) 2 тигез 3 + 4 + 5 + 10 – 11;
3) 6 + 7 тигез 8 + 9;
4) 9 тигез 12 + беркетмәнең аннан соңгы бөтен юллары.”.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 07 июнь
№ 38-ТРЗ